ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

___ 20.09.2025______________ № 732______

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Күпфатирлы йортта урынны үзгәртеп кору һәм (яисә) яңадан планлаштыру үткәрүне килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 22 августындагы 827 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Күпфатирлы йортта урынны үзгәртеп кору һәм (яисә) яңадан планлаштыру үткәрүне килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 22 августындагы 827 номерлы карарына (28.06.2024 № 602 редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Күпфатирлы йортта урынны үзгәртеп кору һәм (яисә) яңадан планлаштыру үткәрүне килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2 бүлегендәге 2.5.1 пунктының 7 пунктчасында түбәндәге сүзләрне төшереп калдырырга:

«Шулай ук РФ Хөкүмәтенең 2005 елның 28 апрелендәге 266 номерлы карары нигезендә, имзалар документларны кабул итүче вазыйфаи зат катнашында куела. Башка очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан гаилә әгъзасының язма рәвештә рәсмиләштерелгән нотариаль таныкланган ризалыгы тапшырыла.»

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып игълан итәргә.

Җитәкче Р.Ф. Хәкимуллин